ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 сентября 2022 г. № 4430

Башкарма комитетның 2017 елның
24 августындагы 4960 номерлы карары
белән расланган Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге территориясендә
беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын
тәэмин итү турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү турында

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль законына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 276-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында» 2017 елның 24 августындагы 4960 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында нигезләмәгә, 2 пунктның 5 пунктчасы үз көчен югалтуны танып, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов